СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**« 19 » март 2020 ел** **№ 98**

**Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2017 елның 07 сентябрендәге № 41 « Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән аерым бер башкарма орган сыйфатында идарә итүдә катнашу яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында» карарына (2019 елның 16 апрелендәге 76 номерлы үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатыннан, Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының 2017 елның 07 сентябрендәге 41 номерлы «Арча муниципаль районы “Яңа Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән аерым бер башкарма орган сыйфатында идарә итүдә катнашу яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында» карары (2019 елның 16 апрелендәге 76 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган Арча муниципаль районы “Яңа Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән аерым бер башкарма орган сыйфатында идарә итүдә катнашу яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә һәм аны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

СОВЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Яңа Кырлай авыл җирлеге Советының
19 март 2020 ел, №98 карарына кушымта

**Арча муниципаль районы “Яңа Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партия идарәсендә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашудан тыш) белән аерым бер башкарма орган сыйфатында идарә итүдә катнашу яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында Нигезләмә**

1. Әлеге Арча муниципаль районы “Яңа Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партия идарәсендә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашудан тыш) белән аерым бер башкарма орган сыйфатында идарә итүдә катнашу яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә, муниципаль хезмәткәрләр) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан җәмәгать оешмасы, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, күчемсез милек милекчеләре ширкәте белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга (алга таба - муниципаль хезмәткәрләрнең түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуы) яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу процедурасын регламентлый.

2. Муниципаль хезмәткәрләрнең коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуы мәнфәгатьләр каршылыгына яки мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлегенә китерергә тиеш түгел.

3. Коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә яллаучы (эш бирүче) вәкиленә рөхсәт бирү турында гариза (алга таба – гариза) әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә муниципаль хезмәткәрләргә Арча муниципаль районы “Яңа Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы (алга таба - җирле үзидарә органы җитәкчесе) исеменә язма рәвештә төзелә.

4. Муниципаль хезмәткәрләр кадрлар эшен алып бару буенча вазыйфа йөкләнгән затка гариза бирә.

5. Гариза коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партия идарәсендә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашудан тыш) белән аерым бер башкарма орган сыйфатында идарә итүдә катнашу яки аларның коллегиаль идарә

органнары составына керү өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу турындагы гаризаларны теркәү журналында (алга таба – Журнал) кадрлар эшен алып бару бурычы йөкләнгән зат тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы нигезендә язылган гариза кергән көнне теркәлә.

Теркәү журналы битләре җирле үзидарә органы мөһере белән расланган, номер сугылган һәм беркетелгән булырга тиеш.

6. Билгеләнгән тәртиптә теркәлгән гаризаның күчермәсе муниципаль хезмәткәргә кадрлар эше алып бару буенча вазыйфалар йөкләнгән зат тарафыннан бирелә яки алу турында хәбәрнамә белән почта аша җибәрелә. Муниципаль хезмәткәргә тапшырылырга тиешле гаризаның күчермәләренә гаризаны теркәгән затның фамилиясен, инициалларын һәм вазыйфасын күрсәтеп, «гариза теркәлгән» тамгасы куела.

7. Кадрлар эшен алып бару буенча вазыйфалар йөкләнгән зат, муниципаль хезмәткәрнең коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашкан очракта мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү яки мәнфәгатьләр каршылыгы булу мөмкинлеген карый һәм дәлилләнгән бәяләмә әзерли.

8. Коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә муниципаль хезмәткәр катнашында мәнфәгатьләр каршылыгы булу яки мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлеге ачыкланган очракта, кадрлар эшен алып бару буенча вазыйфалар йөкләнгән зат дәлилләнгән бәяләмәдә муниципаль хезмәткәр гаризасын канәгатьләндерүдән баш тарту турында тәкъдим кертә.

9. Муниципаль хезмәткәр гаризасы һәм дәлилләнгән бәяләмә кадрлар эше алып бару буенча вазыйфалар йөкләнгән зат тарафыннан гариза теркәлгәннән соң биш эш көне эчендә җирле үзидарә органы җитәкчесенә җибәрелә.

10. Җирле үзидарә органы җитәкчесе гаризаны карау нәтиҗәләре буенча биш эш көне эчендә түбәндәге карарларның берсен чыгара:

муниципаль хезмәткәр гаризасын канәгатьләндерә;

әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән кадрлар хезмәте бәяләмәсендә бәян ителгән нигезләр булганда, муниципаль хезмәткәр гаризасын канәгатьләндерүдән баш тарта.

11. Карар кабул ителгәннән соң ике эш көне эчендә кадрлар эшен алып бару буенча вазыйфалар йөкләнгән зат гаризаны карау нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәткәргә кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

12. Гаризаның төп нөсхәсе һәм аны карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарның күчермәсе муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшенә теркәлә.

Арча муниципаль районы “Яңа Кырлай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партия идарәсендә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашудан тыш) белән аерым бер башкарма орган сыйфатында идарә итүдә катнашу яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәгә
1 нче кушымта

___________________________________________

(җирле үзидарә органы җитәкчесе вазыйфасы, Ф. и. а.и.)

__________________________

(вазыйфаның исеме)

__________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

__________________________

(элемтә өчен телефон)

Гариза
коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партия идарәсендә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашудан тыш) белән аерым бер башкарма орган сыйфатында идарә итүдә катнашу яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен рөхсәт алу турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә, миңа коммерциячел булмаган оешмалар белән аерым бер башкарма орган сыйфатында идарә итүдә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирүегезне сорыйм (ассызыкларга кирәк)

___________________________________________________________________
___________________________________________________________________
___________________________________________________________________
___________________________________________________________________
___________________________________________________________________
___________________________________________________________________

*(муниципаль хезмәткәр башкарырга ниятләгән коммерциячел булмаган оешма турында, үтәлеш башланган көнне кем сыйфатында ниятләгән эшчәнлек турында мәгълүматны күрсәтергә)*

____________________ (дата) ____________ (имза)

Арча муниципаль районы “Яңа Кырлай авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан
коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партия идарәсендә,
һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең
сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының
сайланулы органы, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш,
гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында,
күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашудан тыш) белән
аерым бер башкарма орган сыйфатында идарә итүдә катнашу яки аларның
коллегиаль идарә органнары составына керү өчен
рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәгә
2 нче кушымта

Коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партия идарәсендә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашудан тыш) белән аерым бер башкарма орган сыйфатында идарә итүдә катнашу яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүтурындагы гаризаларны теркәү
Журналы

| № | Гариза биргән муниципаль хезмәткәрнең ф. и.а.и. | Гариза биргән муниципаль хезмәткәрнең вазыйфасы | Кадрлар хезмәтенә гариза керү датасы (кадрлар хезмәте бүлекчәсе, кадрлар эше буенча белгеч) | Гариза кабул иткән муниципаль хезмәткәрнең ф. и. а.и. | Гариза кабул иткән муниципаль хезмәткәрнең имзасы | Муниципаль хезмәткәрнең гаризаның күчермәсен алу турында имзасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |